ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БУРАКОВО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

№ 2-1 от 25.09.2020

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Бураково авыл җирлеге Советының 2013 елның 25 июнрендәге 47-1 номерлы карары белән расланган Спас муниципаль районы "Бураково авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында (N 25-1 от 04.10.2016, N 60-2 от 03.12.2018, N 66-2 от 22.04.2019, N 74 от 05.09.2019, № 88-4 от 30.01.2020 үзгәрешләр белән)

2020 елның 13 июлендәге N 202-ФЗ номерлы Федераль закон, «Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең башка объектларын өлешләп төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Бураково авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Бураково авыл җирлеге Советының 2013 елның 25 июнендәге 47-1 номерлы карары белән расланган Спас муниципаль районы "Бураково авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә (N 25-1 от 04.10.2016, N 60-2 от 03.12.2018, N 66-2 от 22.04.2019, N 74 от 05.09.2019, № 88-4 от 30.01.2020 үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1. Кагыйдәләрнең 29 статьясындагы 5 пунктының дүртенче абзацында ", РФ Шәһәр төзелеше кодексының 55 статьясындагы 6.2 өлеше нигезендә капиталь төзелеш объектының мәйданы үзгәрү очракларыннан тыш, ";

1.2. Кагыйдәләрнең 29 статьясындагы 5 пунктындагы бишенче абзацында «проект документациясе» сүзләреннән соң «РФ Шәһәр төзелеше кодексының 55 статьясындагы 6.2 өлеше нигезендә капиталь төзелеш объекты мәйданын үзгәртү очракларыннан тыш» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны Бураково авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә һәм Спас муниципаль районының рәсми сайтында (http://www.spasskiy.tatarstan.ru) һәм хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

Бураково Авыл җирлеге башлыгы Р.Р.Мингалиев.

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «БУРАКОВСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» СПАССКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
СОВЕТ БУРАКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ